СӨЯ ГОМЕРНЕ, СӨЯ ХАЛЫКНЫ, СӨЯ ХАЛЫКНЫҢ ДӨНЬЯСЫН!

# ДУСЛЫК

ОКТЯБРЬ РАЙОНЫНЫҢ ИҖТИМАГЫЙ-СӘЯСИ ГАЗЕТАСЫ.
ОБЩЕСТВЕННО-ПОЛИТИЧЕСКАЯ ГАЗЕТА ОКТЯБРЬСКОГО РАЙОНА.

Газета 1931 елның 9 июленнән бирле чыга. | №88 (7261) | 23 июль, 1991 ел. СИШӘМБЕ | Бәясе 4 тиен.

## „Уңыш-91" пресс-группасы хәбәр итә

**36 ПРОЦЕНТ.** 22 июльгә районда ашлыгы урылган мәйданнар шулкадәр тәшкил итә. Бу—18852 гектар. Борчакны теземнәргә салу төгәлләнеп килә. Бүгенге көнгә ул 91 процентта, ягъни 6322 гектарда башкарылган. Бу культураның 48 проценты суктырылган. Ә барлык культуралар буенча ул 20 процент тәшкил итә.

Уҗым культуралары өчен җир әзерләү дә дәвам итә. Бу максатка бүгенге көнгә 9352 гектар җир әзерләнде.

Элеваторда яңа уңыш ашлыгын кабул итү бара.

## Игенчелектә көн бурычлары:

*Якын көннәрдә борчак һәм уҗым культуралары уңышын, азык катнашмаларын җыюны төгәлләргә; уҗым культуралары өчен җир әзерләүне тулы куәтенә алып барырга; орлык әзерләү, бер үк вакытта хуҗалыкара алмашу юлы белән аның югары репродукцияле перспектив һәм дефицит сортларын тупларга, туңга сөрү буенча звенолар оештырырга.*

## *Кыр батырларына тигезләнегез!*

### Районның ашлык суктыруда иң әйбәт күрсәткечләргә ирешкән алдынгы комбайнчылары

Беренче багана—токтан урыны, икенче—механизаторның исем-фамилиясе, өченче—хуҗалык исеме, дүртенче—комбайн маркасы, бишенче—урак башыннан 21 июльгә кадәр суктырылган бөртек (центнерларда).

| | | | | |
|---|---|---|---|---|
| 1. | Донсков А. Е. | «Большевик» | ДОН-1500 | 2200 |
| 2. | Әхмәтсафин З. Г. | Хуҗалыкара берләшмә | ДОН-1500 | 1806 |
| 3. | Абрамов В. Д. | «Восход» | ДОН-1500 | 1727 |
| 4. | Шәрәков Ф. Г. | «Алга» | СК-5 | 1692 |
| 5. | Вәлиев З. Х. | XXI партсъезд исем. | СК-5 | 1342 |
| 6. | Ситдыйков С. Ш. | XXI партсъезд исем. | СК-5 | 1333 |
| 7. | Рәхимов И. А. | «Алга» | СК-5 | 1330 |
| 8. | Абдуллин И. Ә. | «Рассвет» совхозы | ДОН-1500 | 1307 |
| 9. | Ендиряков В. Л. | Җыелма отряд | ДОН-1500 | 1300 |
| 10. | Хуҗәхмәтов Х. М. | «Үрнәк» | СК-5 | 1299 |
| 11. | Гобәйдуллин Ә. Г. | «Игенче» | ДОН-1500 | 1268 |
| 12. | Бикиев Ш. Ш. | «Рассвет» совхозы | ДОН-1500 | 1250 |
| 13. | Матвеев В. И. | «Алга» | СК-5 | 1235 |
| 14. | Нилов Н. М. | Синдряков исем. | ДОН-1500 | 1210 |
| 15. | Фәйзуллин М. М. | Җыелма отряд | ДОН-1500 | 1200 |
| 16. | Васильев В. Ю. | «Ленинский путь» | НИВА | 1093 |
| 17. | Мандрейкин Ю. В. | «Ленинский путь» | НИВА | 1087 |
| 18. | Хәлимов Т. Х. | «40 лет Победы» | ДОН-1500 | 1000 |
| 19. | Кыямов Х. К. | «40 лет Победы» | ДОН-1500 | 1000 |
| 20. | Кончев В. А. | «Путь к коммунизму» | СК-5 | 1000 |



Ике бертуганның иңгә-иң торып басуда хезмәт куюы сокландыгч күренеш, шулай бит?!

Алар, Ильяс һәм Вәзир Нурвахитовичлар елның-елында җиң сызганып уракта катнашалар һәм булдыра алганча үзләреннән зур өлеш кертәләр.

Ильяс комбайнчы булып инде ун елдан артык эшли. Шул еллар эчендә байтак тәҗрибә һәм осталык тупларга өлгерде. Хәзер әнә үзе белгәннәрне энесе Вәзиргә өйрәтә. Вәзир исә быел Норлат шәһәрендәге профессиональ-техник училищеның икенче курсын бетерде.

Ике бертуган бүгенге көнгә барлыгы 786 гектар мәйданда ашлык суктырдылар һәм беренче урынга чыктылар. Хафизовлылар якын көннәрдә борчак һәм арыш суктыруны төгәлләргә исәплиләр. Бары 50 шәр гектар мәйданда җыелмаган борчак һәм арыш калды.

Сафиуллиннарның буш вакытлары, гомумән юк. Аларның тагын бер матур гадәтләре бар. Ял сәгатьләрендә атта йөрергә яраталар. Һәр елны сабантуйда атлар узыштыру ярышларында катнашалар.

Рәсемдә: абыйлы-энеле Ильяс һәм Вәзир Сафиуллиннар.

## Эшләр комплекслы бара

Игенчеләр өчен иң киеренке көннәр бүген. Басуларда үстерелгән уңышның бөртеген дә югалтмыйча җыеп алуга бар тырышлыкларын туплап эшлиләр алар.

«Россия» колхозы басуларында да комбайннар гөрелтесе иртәнге кояш чыгуга башлана. Киеренке эш бара монда. Шөкер, көннәр дә аязып китте. Хәзер бөтен ышаныч, бөтен өмет—механизаторларда. Аларның уңган-булганлыгына, эш тәҗрибәсенә, осталыгына җитди сынау көннәре. Бүгенге көнгә Николай Германович Михеев —1226, Георгий Андреевич Имуков —1110, Анатолий Степанович Терентьев—1108, Юрий Николаевич Саврандейкин—924 центнер ашлык суктырып эштә хезмәттәшләрен әйдәп баралар.

Колхоз буенча 450 гектарда арыш, 150 гектар мәйданда борчак теземнәргә салынып, шушы мәйданнарның 440 гектарында ашлык суктырылып бетте.

Россиялеләр күршеләренә дә бу җаваплы чорда ярдәм итәргә теләп алыналар. Алар «Төрнәс» совхозына 120 гектарда борчакны теземнәргә салырга булыштылар. Ызандашларның мондый ярдәмләшүе ике хуҗалыкка да файдалы. Яшел урак вакытында да россиялеләр күршеләренә уртактан 100 тонна печән хәзерләшкәннәр иде, ә хуҗалар исә, аны рәхмәт йөзеннән, тулаем бирергә булганнар.

Хуҗалыкта терлекләргә кышлату чорына мул азык базасы булдыру да игътибардан төшми. Хуҗалыкта 300 тонна печән хәзерләнгән, 1700 тонна сенаж салынган. Хәзер бер учма саламны да әрәм-шәрәм итмичә эскертләргә кую эшләре бара.

Язманы шуның белән генә тәмамласак, хуҗалыкта бүгенге көндә башкарыла торган эшләрне яктырту һич тулы булмас иде. Чөнки игенче бүгенге урып-җыю, яшел урак мәшәкатьләре өстенә, киләсе уңыш турында да хыяллана.

Бөртеклеләргә билгеләнгән җирнең 50 процентына хуҗалык быел уҗым бодае чәчәргә уйлый. Безнең климат шартларында бу игенчелектә бик дөрес юнәлеш, чөнки ул һава шартларына карамастан тотрыклы уңыш алырга мөмкинлек бирәчәк.

150 гектар мәйданда көзгә чәчеләчәк чиста пар җирләренә 12000 тонна органик ашламалар чыгарылды.

Гектарына 60 килограмм исәбеннән минераль ашлама кертелде.

Урактан бушаган җирләргә хәзер сөрү тракторлары чыкты.

Тулаем алганда, «Россия» колхозында барлык эшләр дә комплекслы алып барыла, чөнки башкарыла торган эшләрнең һәркайсы мөһим, һәркайсы кичектергесез. Моны хуҗалыкта яхшы аңлыйлар.

Р. ШӘЙХУЛЛИНА.

## Кырларда хезмәт шавы

**«Чишмә» колхозында борчак 200, арыш 555 гектар мәйдан били. Бүгенге көнгә борчак тулысынча чабылып бетте, ә арыш 410 гектарда теземнәргә салынды.**

Соңгы вакытларда һава шартларының әйбәт торуы игенчеләргә иркенләп эшләргә мөмкинлек бирде. Комбайнчылар зур тырышлык куеп эшлиләр.

Наил Хәсәнҗанов колхозда тәҗрибәле комбайнчылардан санала. Ул үзенең «ДОН-1500» комбайнында урак башланганнан бирле барлыгы 1400 центнер ашлык суктырды. Бүгенге көнгә улы Илшат Хәсәнҗанов та үзенең «Нива» комбайнында 910 центнер ашлык суктырды. Илшат хуҗалыкка үзе теләп ярдәмгә килде.

Комсомол егет Айдар Вилданов та сынатмый. Икенче генә ел эшләвенә карамастан, әйбәт кенә нәтиҗәләргә ирешә. Аның урак башланганнан бирле суктырылган ашлыгы—1150 центнер.

Норлат элеваторына ашлык ташуда КамАЗ шоферы Айрат Әхмәтов һәм Бөгелмә технологик-транспорт идарәсеннән ярдәмгә килгән шоферлар да зур өлгерлек күрсәтәләр.

Борчак чабуда Әнәс Камалетдинов җитәкчелегендәге аренда звеносы аеруча яхшы эшләде. Арышны теземнәргә салуда исә 25 ел эш стажы булган Нәҗип Вилданов һәм Ринат Хәбибуллин фидакарьлек үрнәге күрсәтәләр.

Чишмәлеләр шушы көннәрдә борчак суктыруга керештеләр.

Н. ӘХМӘТВӘЛИЕВ,
агроном.

## Киеренке көннәр

«1 Май» колхозы кырларында киеренке эш кайный. Комбайнчылар хәзерге көндә җиң сызганып җилләтелгән теземнәрне тизрәк югалтуларсыз суктырып алырга ашыгалар.

Хәзерге көндә 150 гектарда борчак, 100 гектарда арыш суктырылды инде.

Хуҗалыкта 205 гектар мәйданда борчак теземнәргә салынды. Николай Максимович Попов , Валерий Александрович Иванов, Михаил Валерьевич Семенов бу эштә көнлек нормаларын күпкә арттырып башкардылар.

Геннадий Васильевич Итрин —141, Анатолий Яковлевич Семенов —159, Николай Сергеевич Яковлев—53 гектар мәйданда арышны теземнәргә салдылар.

Шул ук вакытта салам эскертләү дә бара.

Н. ГРИГОРЬЕВ,

# Ял итәр чак түгел







**Фото-информация**

Рәсемнәрдә: өстә—сулда колхозның эретеп ябыштыручысы Иван Геннадьевич Леваков; уңда— В. Яргунов комбайны эштә; аста—сулда комбайнчы Ю. Н. Васильев һәм аның ярдәмчесе В.Евдокимов; уңда—Никифоровларның гаилә экипажы; Кузьма Филиппович һәм улы 99 нчы СПТУ курсанты Валерий.



Иртәдән күкне болыт каплаган иде. Механизаторлар зур өмет белән һаваны күзәттеләр. Күк йөзендәге соры болытлар арасыннан аз гына елмаеп алган кояш та көннең матураюын бик үк вәгъдә итми иде. Юк-юк та яңгыр сибәләп ала. Мондый чакта ничек кырга чыгасың?! Комбайнчылар борчулы йөзләрен һаман күккә төбиләр. Кыр кораблары янәдан тик тора. Әмма яхшы хуҗа беркайчан да эшсез тормый. Ә Мичурин исемендәге колхозда җирнең чын хуҗалары аз түгел. Әнә табигать көйсезлеге аркасында буш торган арада да алар техниканы карау белән мәшгульләр. Кырга чыккач тоткарлыклар булмасын, янәсе. Шунысы әйбәт, ремонтчылар да кул астында ук. Алар механизаторларга ярдәмнәрен кызганмыйлар, шунда ук килеп җитәләр.

Ә игеннәрне урдыру өчен вак яңгыр әллә ни комачауламый. Комбайннар тулы көчкә эшлиләр, үз артларыннан авыр башакларын түбән иеп арышны тигез рәтләр итеп җиргә салып баралар.

---

## Җәйләү яме—сөт белән

Ульянов исемендәге колхозның җәйге лагере матур Чирмешән елгасы буена урнашкан. Ләкин малларны ашатмасаң-эчертмәсәң, яхшы итеп карамасаң, табигать хозурлыгы гына продукция бирүне арттырмый.

Безнең ферма эшчәннәре сыерларны көнозын болыннарда көтәләр, иртә-кич мул итеп яшел азык бирәләр. Болар өстенә аларны төнгә кабат көтүгә алып чыгалар. Көтүчеләребез дә бер дигән бит безнең. Рәмис Әхмәтшин,Заһир Яруллин малларны мул азыклы көтүлекләрдә йөртәләр. Рәмис әле бу эштә яңа кеше. Ә Заһир гомере буена терлекчелектә. Сыерның сөте телендә икәнлеген яхшы белә.

Боларның барысы да уртача савымның сизелерлек артуына китерде. Хәзер колхоз буенча һәр сыердан уртача 12 шәр килограмм сөт алына. Алдынгы савучыларның күрсәткече тагын да югары. Әнә Әлфия Хөснуллина үзенә беркетелгән һәр сыердан 23 әр килограмм сөт сава. Миннеруй Яруллина, Галия Гатауллина да алдынгы савучының үкчәсенә басып киләләр.

Товарлыклы-сөтчелек фермасы мөдире Гәрәй Гатауллин да тырыш булып чыкты. Эш өчен җан атып йөри. Инде фермалар көзгә маллар кабул итәргә бүгеннән әзер. Абзарлар эчтән-тыштан ап-ак итеп агартылган, җиһазлар, кирәк-яраклар ремонтланган.

Сыер савучылардан мал симертүчеләр дә калышмый. Алар да җәй муллыгыннан файдаланып калырга омтылалар. Яшь бозаулар карачылар Әлфия Йосыпова, һәм Әминә Кәлимуллина сыната торганнардан түгел. Алар бозауларның 800 грамм тәүлеклек үсеш бирүенә ирешәләр. Ә Бибизә Галиуллина алардан алган бозауларны 6 айгача үстерә. Аның маллары 600 әр грамм тәүлеклек артым бирәләр.

Мул продукция алуда оператор Юныс Закировның да өлеше күп керә. Ул фермадагы барлык механизмны хәрәкәткә китерә.

Сүз дә юк, ферма эшчәннәре булдыра, тату эшләгәндә генә уңышка ирешеп була. Ә бездә коллектив дус һәм булдыра.

**З. КӘРИМОВА,**
хәбәрче.

---

## Алда имтиханның зурысы

Көн заказ биргән шикелле аяз. Шуңа да, иртәнге сәгатьләрдә үк инде басуда комбайннар гөрелтесен ишетүе күңелгә аеруча якын.

—Кырга унҗиде комбайн чыкты,—дип аңлата совхоз директоры Михаил Васильевич Немов.—Быел кыр имтиханын уңышлы тапшырачагыбызга шик юк.

Сүзгә агроном селекционер Светлана Гурьяновна Евстахова да кушыла:

—Бу арыш басуында җиде «Нива» комбайны эшләячәк. Игенчеләр кырга оператив чыктылар, шуның өчен борчылырлык сәбәпләр дә юк төсле.

Иркен басу буйлап комбайннарга таба юл тотабыз. Тузан өермәсенә күмелеп якында гына бер комбайн туктап калды. Юрий Максимов булып чыкты ул. Басуда инде быел тугызынчы елын эшли. Димәк, аңар инде моңарчы да җитди имтиханнар тотарга туры килгән. Шунысы куандыра, совхоз комбайнчыларының күбесенең хезмәт стажлары Юрийныкы шикелле булып чыкты. Бу—хуҗалыкта тәҗрибәле комбайнчыларга аптырамыйлар дигән сүз.

«Мамык» совхозында бөртекле һәм бөртекле-кузаклылар барлыгы 814 гектар мәйданны били. Игенчеләр аның 100 гектарын суктырганнар инде. Сары диңгез басуы беренче карашка бер дә кимемәс төсле күренсә дә, кырның байтагы бушап калган инде. Комбайн бункерлары тулганны бер читтә түзем генә шоферлар көтеп тора.

ГАЗ-53 автомашинасында Веналий Иванович Гаврилов, Василий Валентинович Захаров, ЗИЛ-543 автомашинасында Александр Егорович Сергеев, КамАЗ машинасында Александр Порфирьевич Гаврилов шактый ашлык ташырга өлгергәннәр.

Мамыклылар яңгырлы көннәрдә дә эштән тукталмаганнар.

—Мондый көннәрдә турыдан суктырдык, ә суктырылган ашлыкны АВМ аша чыгарып фуражга әзерләдек,—ди Михаил Васильевич.—Әле менә килешү буенча безгә «Агропромхимия» берләшмәсеннән биш машина килергә тиеш иде.

Һәркем канәгать. Димәк, эш көйле барганда күңел тынычланып кала, җанга рәхәтлек иңә. Аркадий Гурьянов, Николай Герасимов, Виктор Молчанов һәм башкалар шикелле ир-егетләр булганда игеннәрнең үз вакытында җыеп алыначагына шик юк.

Алда әле зур имтихан тора. Бу имтиханны быел кайсы комбайнчы аеруча уңышлы тапшырыр икән? Узган елгы кыр батыры Аркадий Гурьяновмы, әллә башка берәүме?

**Г. РӘХИМОВА.**

